КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 декабрь г.Казань № 1206

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 апрель, 303 нче карары белән расланган Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә агросәнәгать комплексы өлкәсендә Татарстан Республикасының күргәзмә һәм башка чараларда катнашуына, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә агросәнәгать комплексы өлкәсендә күргәзмә һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә агросәнәгать комплексы өлкәсендә Татарстан Республикасының күргәзмә һәм башка чараларда катнашуына, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә агросәнәгать комплексы өлкәсендә күргәзмә һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 30 апрель, 303 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 июнь, 441 нче; 2017 ел, 29 август, 619 нчы; 2017 ел, 24 ноябрь, 897 нче; 2018 ел, 21 сентябрь, 814 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә агросәнәгать комплексы өлкәсендә Татарстан Республикасының күргәзмә һәм башка чараларда катнашуына, шулай ук Татарстан

Республикасы территориясендә һәм аннан читтә агросәнәгать комплексы өлкәсендә күргәзмә һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау максатларында, юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның беренче абзацында «кабул итү планлаштырылган айның бересенә» сүзләрен «планлаштырылган кабул итү көненә кадәр 15 эш көненнән артмаган датага» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин